**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4986**
**06.09.2018**

Җир участогын субарендага тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ санлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 6 сентябрендәге 5433 нче карары белән (Башкарма комитетның 2016 елның 29 июнендәге 3353 нче карары редакциясендә) расланган җир участогын субарендага тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.4 пунктның 7-10 абзацларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Вәкиллекле органының 2005 елның 8 декабрендәге 6/5 нче карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы (алга таба – шәһәр Уставы) (Челнинские известия, 10.12.2005, №235-237, 30.12.2005, №249);

Башкарма комитетның «Муниципаль һәм дәүләт хезмәтләре исемлеген раслау турында» 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары (алга таба – Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары);

Башкарма комитетның 2017 елның 28 декабрендәге 1210-р санлы боерыгы белән расланган Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезнамә (алга таба – Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе турында нигезнамә);

Башкарма комитетның 2014 елның 11 мартындагы 147-р санлы боерыгы белән расланган Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының эш регламенты (алга таба – Эш регламенты);»;

2) 2.1 пункттагы «2013 елның 9 апрелендәге 2393 нче карар» сүзләрен «Башкарма комитетның 2016 елның 13 маендагы 2363 нче карары» сүзләренә алмаштырырга;

3) 2.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга мөрәҗәгать итү зарурлыгын исәпкә алып, әгәр туктату мөмкинлеге Россия Федерациясе законнарында каралган булса, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату срогы | Гариза теркәлгән вакыттан башлап 10 көннән[1] артык түгел.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктату каралмаган. | |

4) 2.5 пунктның 5 пунктчасын төшереп калдырырга;

5) 2.6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм башка оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге | 1) Бердәм дәүләт юридик затлар реестрыннан өземтә;<br>2) Бердәм дәүләт шәхси эшмәкәрләр реестрыннан өземтә;<br>3) Күчемсез милек объекты (ҖУ) турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә;<br>4) Күчемсез милек объектының төп характеристикалары һәм аңа теркәлгән хокуклар турында Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрыннан өземтә. | 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль законның 7.1 маддәсе |

6) 2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен килешенү таләп ителә торган Башкарма комитет структур бүлекчәләренең исемлеге | Муниципаль хезмәтне килешенү таләп ителми. | |

[1] Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы административ процедураларны гамәлгә ашыру өчен минималь кирәкле суммар сроктан чыгып билгеләнгән. Административ процедураларның дәвамлылыгы эш көннәре белән исәпләнә.

7) 2.8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүне кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | 1) Документлар тиешле булмаган зат тарафыннан тапшырылу;<br>2) Тапшырылган документлар Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар исемлегенә туры килмәү;<br>3) Гаризада һәм аңа теркәлгән документларда алдан килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлегенә төшенергә мөмкинлек бирми торган җитди бозулар;<br>4) Документларны тиешле булмаган органга тапшыру. | |

8) 2.9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки кире кагу өчен нигезләрнең тулы исемлеге | Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигез: җир участогына карата суд бәхәсе булу.<br>Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документларда дөрес булмаган мәгълүматлар ачыклану кире кагу өчен нигез булып тора. | |

9) 2.13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запросын теркәү срогы, шул исәптән электрон рәвештә | Гариза кергән вакыттан башлап бер көн эчендә.<br>Электрон рәвештә ял (бәйрәм) көнендә кергән запрос ял (бәйрәм) көненнән соң килүче эш көнендә теркәлә. | |

10) 2.15 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.15. Муниципаль хезмәттән файдалана алу мөмкинлеге һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтелгәндә гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара эшчәнлегенең саны һәм аларның | Муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлегенең күрсәткечләре булып түбәндәгеләр тора:<br>бинаның җәмәгать транспорты йөри торган зонада урнашуы;<br>кирәкле санда белгечләрнең булуы, шулай ук мөрәҗәгать итүчеләрдән документлар кабул | |

| | | |
|---|---|---|
| дәвамлылыгы, муниципаль хезмәтне дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында алу мөмкинлеге, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләре кулланып | итеп алу өчен кирәкле санда бүлмәләрнең булуы;<br>мәгълүмат стендларында, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;<br>инвалидларга башка затлар белән бер үк дәрәҗәдә хезмәттән файдалануга комачаулый торган киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты түбәндәгеләрнең булмавы белән характерлана:<br>документлар кабул иткәндә һәм гариза бирүчеләргә документлар биргәндә чиратлар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтү срокларын бозулар;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең эш итүләренә (эш итмәүләренә) шикаятьләр;<br>муниципаль хезмәт күрсәтүче муниципаль хезмәткәрләрнең гариза бирүчеләргә карата тупас, игътибарсыз мөнәсәбәтенә шикаятьләр.<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос биргәндә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алганда муниципаль хезмәт күрсәтүче вазыйфаи затның һәм гариза бирүченең бер тапкыр үзара эшчәнлеге күздә тотыла. Үзара эшчәнлек дәвамлылыгы регламентта билгеләнә.<br>Муниципаль хезмәт дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәктә (алга таба – күпфункцияле үзәк), күпфункцияле үзәкнең ерактагы эш урыннарында күрсәтелгәндә консультация бирүне, документларны кабул итү һәм бирүне күпфункцияле үзәк белгече гамәлгә ашыра. | |

11) 3.4.2 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге пунктта билгеләнгән процедуралар түбәндәге срокларда гамәлгә ашырыла:

- Росреестр белгечләре тарафыннан җибәрелә торган документлар (мәгълүматлар) буенча, өч эш көненнән артмаган срокта;

- башка мәгълүмат бирүчеләр буенча – федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән очракта, документ яки мәгълүмат бирә торган органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап биш көн эчендә.»;

12) 4.2 пункттагы «муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан» сүзләренә алмаштырырга;

13) 4.4 пункттагы «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

14) 4 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 4.5 пункт белән тулыландырырга:

«4.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә Башкарма комитет эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге аша гамәлгә ашырыла.»;

15) 5 бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләрнең, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгечләренең карарларына һәм эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе.»;

16) 5.1 пунктта:

- беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар Башкарма комитетның муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы хезмәткәрләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) судка кадәр тәртиптә – Башкарма комитетка, күпфункцияле үзәк хезмәткәрләре буенча – күпфункцияле үзәккә яисә күпфункцияле үзәкне оештыручы булып исәпләнгән гавами-хокукый берәмлекнең тиешле дәүләт хакимияте органына (җирле үзидарә органына) шикаять бирергә хокуклы.»

- 5 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең норматив хокукый актларында каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту;»;

17) 5.1. пунктны түбәндәге эчтәлектәге 8, 9 пунктчалар белән тулыландырырга:

«8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату.»;

18) 5.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.2. Шикаять язма рәвештә кәгазь йөрткечтә яки электрон төрдә бирелә.

Шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтыннан (http://www.nabchelny.ru), күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Татарстан Республикасының бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан (http://uslugi.tatar.ru/), Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталыннан (http://www.gosuslugi.ru/) файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.»;

19) 5.3. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.3. Шикаятьне карап тикшерү срогы – ул теркәлгән көннән башлап унбиш эш көне эчендә. Башкарма комитетның, Башкарма комитет вазыйфаи затының, күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгеченең гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтүдән баш тартуыннан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта яки шундый төзәтүләрнең билгеләнгән срогы бозылудан риза булмыйча шикаять бирелгән очракта – ул теркәлгән көннән башлап биш эш көне эчендә.»;

20) 5.4 пунктның 1 пунктчасын «Башкарма комитетның муниципаль хезмәткәре» сүзләреннән соң «күпфункцияле үзәк, аның җитәкчесе һәм (яки) белгече,» сүзләре белән тулыландырырга;

21) 5.4 пунктның 3 пунктчасын «, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк белгечләре;» сүзләре белән тулыландырырга;

22) 5.4 пунктның 4 пунктчасын «, күпфункцияле үзәк, күпфункцияле үзәк белгечләре;» сүзләре белән тулыландырырга;

23) 5.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.7. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документлардагы хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.»;

24) 5 бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 5.9, 5.10 пунктлар белән тулыландырырга:

«5.9. Шикаять тулысынча яки өлешчә канәгатьләндерелгән очракта, кимчелекләрне бетерү максатында кабул ителергә тиешле чаралар билгеләнә.

Шикаятьләрне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

5.10. Гариза бирүчеләр Башкарма комитетның, аның вазыйфаи затларының, шулай ук күпфункцияле үзәкнең, күпфункцияле үзәк белгечләренең карарларына, эш итүләренә (эш итмәүләренә) Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә шикаять бирергә хокуклы.»;

25) җир участогын субарендага тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 2 нче кушымтада «Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары» сүзләрен «Башкарма комитет Җитәкчесе» сүзләренә алмаштырырга;

26) кушымтаны (белешмә) әлеге карарга кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 6 сентябрендәге
4986 нчы карарына
кушымта

Җир участогын субарендага тапшыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмә)

Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен җаваплы
һәм аның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның
реквизитлары

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 30-55-42 | kancel.chelny@tatar.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы | 30-55-54 | uzioip@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы урынбасары | 30-55-54 | uzioip@yandex.ru |
| Башкарма комитет җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсенең җиргә кагылышлы аренда мөнәсәбәтләрен җайга салу бүлеге башлыгы | 30-55-54 | uzioip@yandex.ru |
| Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе бүлеге белгече | 30-55-54 | uzioip@yandex.ru |

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе Г.К. Әхмәтова